**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Югары Стәрле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Югары Стәрле авылы № 117-73 13 ноябрь 2018 ел

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Югары Стәрле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советы карары проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына яраклы рәвештә һәм «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү объектларын тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатларында

Югары Стәрле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2012 елның 12 октябрендәге 47 номерлы карары белән расланган (06.09.2013 №66, 20.03.2014 №87, 22.08.2014 №107, 04.09.2017 №61-38 карарлар редакциясендә) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы бирелгән карар проектын хупларга. (Кушымта №1)

2. “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Югары Стәрле авыл җирлеге Советының 2012 елның 12 октябрендәге 47 номерлы карары белән расланган (06.09.2013 №66, 20.03.2014 № 87, 22.08.2014 №107, 04.09.2017 №61-38 карарлар редакциясендә) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының “Югары Стәрле авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм

өстәмәләр кертү турында” карары проекты буенча халык алдында тыңлауларны уздырырга.

Билгеләргә:

- үткәрү вакыты - 2018 елның 26 ноябреннән 2018 елның 28 декабренә кадәр;

-үткәрү урыны - Югары Стәрле авылы, Совет урамы, 32г йорт;

- түбәндәге адрес буенча 2018 елның 28 декабренә кадәр язма тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертелергә мөмкин - Югары Стәрле авылы, Совет урамы, 32г, Азнакай муниципаль районының Югары Стәрле авыл җирлеге Башкарма комитеты (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр (төшке ашка тәнәфес 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

4. Гавами тыңлауларны үткәрү буенча эшче төркем төзергә:

-Сабирҗанова Л.С. - Югары Стәрле авыл җирлеге башлыгы;

-Габделхакова И.М. - Югары Стәрле авыл җирлегенең 5 нче округ депутаты;

-Сунагатов И.М. - Югары Стәрле авыл җирлеге Советының 2 нче округ депутаты.

5. Гавами тыңлаулар уздыру буенча эшче төркемгә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2012 елның 12 октябрендәге 47 номерлы карары белән расланган (06.09.2013 №66, 20.03.2014 № 87, 22.08.2014 №107, 04.09.2017 №61-38 карарлар редакциясендә) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча халык алдында тыңлаулар уздыруны тәэмин итәргә, гражданнарны кабул итәргә һәм аларның тәкъдимнәрен исәпкә алырга.

6. Торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссия гавами тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, чираттагы утырышны карауга кертергә тиеш.

7. 2018 елның 19 ноябреннән дә соңга калмыйча, әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.С. Сабирҗанова

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Югары Стәрле авыл җирлеге
Советы 2018 елның
13.11.2018 №17-73 карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Югары Стәрле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

_________ авылы №___ __ _________ 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2012 елның 12 октябрендәге № 47 номерлы (06.09.2013 №66, 20.03.2014 №87, 22.08.2014 №107, 04.09.2017 №61-38 карарлар редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 463-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чиста һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатларында,

Югары Стәрле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2012 елның 12 октябрендәге № 47 номерлы (06.09.2013 №66, 20.03.2014 №87, 22.08.2014 №107, 04.09.2017 №61-38 карарлар редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль

берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктының икенче, өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Территорияне төзекләндерү - гражданнарның яшәү шартларының уңайлылыгын тәэмин итүгә һәм арттыруга, муниципаль берәмлек территориясенең санитария һәм эстетик торышын яхшыртуга, торак пунктлар территорияләрен һәм мондый территорияләрдә урнашкан объектларны, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналарны, корылмаларны, якын территорияләрне карап тотуга юнәлдерелгән әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру эшчәнлеге.

Төзекләндерү элементлары - территорияне төзекләндерүнең состав өлеше буларак кулланыла торган декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, җиһазларның һәм бизәлешнең төрле төрләре, шул исәптән биналарның, корылмаларның фасадлары, кече архитектура формалары, төзелеш һәм корылмалар, мәгълүмати щитлар һәм күрсәткечләр.».

1.2. түбәндәге эчтәлекле 2.10.3.1 пункт өстәргә:

«2.10.3.1. Йорт билгеләрендәге, тышкы мәгълүмат чараларындагы мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы законнар таләпләрен үтәгән килеш урнаштырылырга тиеш. Ике яки аннан да күбрәк тел кулланган очракта, текстлар эчтәлек һәм техник бизәлеш буенча тиңдәш булырга, грамоталы һәм аңлаешлы итеп башкарылырга тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.